ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 57 2017 елның 26 гыйнвары

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 10 февралендәге 106 номерлы карары белән расланган реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге ФЗ-210 номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» карары нигезендә, карар бирәм:

1.Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 10 февралендәге 106 номерлы карары белән расланган реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне расларга (кушымта).

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

А. Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 26 гыйнварындагы
57 номерлы карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының
2016 елның 10 февралендәге 106 номерлы карары белән расланган
реклама конструкциясен урнаштыруга һәм
эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына үзгәрешләр

1.1. 1.3. пунктының икенче абзацында «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм архитектура идарәсе (алга таба – Идарә)» сүзләрен «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының тышкы реклама белән эшләү секторы (алга таба – Сектор)» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Административ регламент тексты буенча билгеле килештәге «Идарә» сүзен билгеле килештәге «Сектор» сүзенә алмаштырырга.

1.3. 1.3. пунктының 1.3.1. пунктчасындагы алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ял һәм туклану өчен тәнәфес вакыты: 12 сәгатьтән 13 сәгатькә кадәр».

1.4. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.6. пунктына түбәндәге редакциядә 3 пунктча өстәргә:

«3) ЮЗБДРдан мәгълүматлар яисә ШЭБДРдан мәгълүматлар».

1.5. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.7. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының иҗтимагый берләшмәләр белән элемтәләр һәм милли мәсьәләләр бүлеге белән килештерү».

1.6. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.13. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза кергән көнне административ регламентның 3 нче бүлегендә билгеләнгән тәртиптә башкарыла».

1.7. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исеме» баганасының 2.14. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган урыннарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматлар урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр».

1.8. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.14. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм урыннарда гамәлгә ашырыла.

Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алуы тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм алар чикләрендә күчеп йөрү).

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.».

1.9. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.15. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора;

урынның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашкан булуы;

кирәкле белгечләр саны, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләр булу;

муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат такталарында, «Интернет» челтәрендә, Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында тулы мәгълүмат булу;

законда каралган инвалидлар өчен үтәрлек шартлар булу.

Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:

гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү һәм бирү чиратлары;

муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;

муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр;

муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ), КФҮнең читтән торып эш урыннарында муниципаль хезмәт күрсәткәндә, консультация, документларны кабул итү һәм бирүне КФҮ белгече башкара.».

1.10. 3.1. пунктындагы 3.1.2. пунктчасында «5 нче кушымтада» сүзләрен «4 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга.

1.11. 3.3. пунктының 3.3.2. пунктчасындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Регламентның 2.5. пунктында каралган гариза һәм документлар кабул итү;».

1.12. 3.3. пунктының 3.3.2. пунктчасындагы дүртенче абзацында «кабул итү һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.13. 3.3. пунктының 3.3.2. пунктчасындагы җиденче абзацында «яки мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.14. 3.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә 3 пункт белән тулыландырырга:

«3) ЮЗБДРдан мәгълүматлар яисә ШЭБДРдан мәгълүматлар».

1.15. 3.5. пунктының 3.5.2. пунктчасын түбәндәге редакциядә абзац белән тулыландырырга:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләсе Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан оештырылган комиссиядә каралырга мөмкин».

1.16. 3.7. пунктының 3.7.1. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7.1. Идарә белгече Рөхсәт яки Баш тарту турында карарны терки, кабул ителгән карар турында гариза бирүчегә хәбәр итә. Мөрәҗәгать итүче килгәч, имза куйдырып, Рөхсәт яисә Баш тарту турында карарны бирә. Әлеге абзацта күрсәтелгән процедура 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче килмәгән очракта, Идарә белгече, алдагы процедура тәмамланганнан соң өч көн эчендә, Рөхсәт яки яки Баш тарту турында карарны алу турында хәбәрнамә белән почта аша заказлы хат белән җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән яки почта аша җибәрелгән Рөхсәт яки Баш тарту турында карар.».

1.17. 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеген үтәүне агымдагы тикшерү Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары тарафыннан башкарыла».